РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
КРЯШ-ШУРАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕРЭШ-ШУРАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423978, Р.Т. Муслюмовский район, с. Кряш-Шуран, ул. Центральная 6а,
Kshur.Mus@tatar.ru тел. (8-85556) 3-35-45
ИНН 1629003978, КПП 162901001, ОГРН 1061687005203, ОКАТО 92242825000,
ОКТМО 92642425

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№8** **2021 ел 07 апрель**

**«Керэш-Шуран авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитетының2017 елнын 27 февраленен, 4 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Төп муниципаль актка үзгәрешләр кертә торган муниципаль акттагы хаталарны төзәтү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 ел, 27.02, 1 номерлы карары белән расланган « Керэш-Шуран авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6.2 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.2. 2.8 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.9 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

1.4 3.3 пунктының 2) пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) ведомствоара гарызнамәләр җибәрә:

салым органында исәпкә кую, салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар барлыгы (юклыгы) турында Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Керэш-Шуран авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: Р.Г.Сафиуллин